СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Молодежная ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге башлыгы карары**

**05 октябрь 2023 ел** **N 1**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Алан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы карарга юл өслеге төрен алыштыру өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Алан авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Уставының 25 статьясына нигезләнеп, Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Алан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы карарга юл өслеге төрен алыштыру өлешендә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 16 октябрендә 10 сәг. 00 минутта Алан авылы, 1 Май урамы, 1а йорт адресы буенча билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләгә расларга:

«Алан авылында 1 Май урамыннан 1а йортына кадәр, 1 Май урамыннан 11а йортыннан 11б йортына кадәр юл-урам челтәренең юл өслегенә асфальт-бетон җәю»не «Алан авылында 1 Май урамындагы 11б йортыннан алып Х. Такташ урамындагы 26 йортка кадәр юл-урам челтәренең юл өслегенә вак таш җәю»гә алыштырып, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Алан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү белән килешәсезме?»

«Әйе» «Каршы»

3. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Алан авылына гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Урта Курса авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Алан авылы, Һ. Такташ ур., 23 йорт каршында урнашкан мәгълүмати стендта, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина